**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге башлыгы карары**

**2022 елның 11 ноябре** **№ 4**

**«Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1 2022 елның 24 ноябренә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Пчеловод авылы, Үзәк урам, 24 адресы буенча урнашкан Пчеловод авылы клубы бинасында үткәрергә.

2 2022 елның 24 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Пчеловод авылы, Үзәк урам, 24 адресы буенча урнашкан Пчеловод авылы клубы бинасында үткәрергә.

3 Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Пчеловод авылында урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Пчеловод авылының Урман урамындагы юлларга вак таш җәю (вак таш сатып алу, ташу, җәю); проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Пчеловод авылының артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу; килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- Пчеловод авылы чишмәсе янындагы территорияләрне һәм ял зоналарын төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру; килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- Пчеловод авылы зиратын коймалау өчен материал сатып алу; килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- Пчеловод авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Пчеловод авылындагы балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Пчеловод авылында су башнялары янына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- Пчеловод авылының Урман урамына асфальт җәю һәм вак таш җәеп ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү?

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Югары Чура авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы: В.Н. Андреев